КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 июнь г.Казань № 508

Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 321 нче карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карага теркәлгән Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныырга:

«Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 27 апрель, 253 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 14 ноябрь, 841 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин